| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ФЕДОТОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ФЕДОТОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 31 октябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Кузьминовка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлеге Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2020 елда Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән (дүрт һәм аннан да күбрәк бала), Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны Федотовка авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Федотовка авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы В.И.Павлова